Казан шәһәре Думасының
2024 елның 7 августындагы 10-31 номерлы карары

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш территориаль зонасы (ОЖ) чикләрен һәм чикләрендә территорияләрне комплекслы үстерүне гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территорияләр (КРТ) чикләрен үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитеты тәкъдимен, Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе каршындагы Җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясе бәяләмәсен һәм 2024 елның 21 мартыннан 2024 елның 4 апреленә кадәр уздырылган җәмәгатьчелек белән фикер алышулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Казан шәһәре Думасы **карар бирде**:

1. Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5-8 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (алга таба – Кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасында, территориаль зона – катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасына (ОЖ) (54 номерлы контур) чикләренә әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә территорияне кертеп, территориаль зона – катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы (ОЖ) (53 номерлы контур) чикләрен үзгәртергә;

1.2. чикләрендә территорияләрне комплекслы үстерүне гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территорияләр картасы фрагментын әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендә бирергә;

1.3. әлеге карарның 1.1 пунктчасында күрсәтелгән территориаль зонаның үзгәрә торган чикләрен Кагыйдәләр составындагы шәһәр төзелешен зоналаштыруның түбәндәге карталарында чагылдырырга:

- шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы;
- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: урам-юл челтәре, табигать-рекреация комплексы, махсус билгеләнештәге яшелләндерү, яр буе территорияләре күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: территорияне югары интенсивлыкта файдалану, шәһәр төзелешендә әһәмияткә ия территорияләр күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- территориаль зоналарның ярдәмче зоналары: тарихи җирлек ярдәмче зонасы күрсәтелгән шәһәр төзелешен зоналаштыру картасы;

- чикләрендә территорияләрне комплекслы үстерүне гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территорияләр картасы;

1.4. Кагыйдәләргә 1 номерлы кушымтаны әлеге карарга 3 номерлы кушымта (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) нигезендә территориаль зоналар чикләре урнашу урынының график тасвирламасы белән тулыландырырга;


1.5. Кагыйдәләргә 2 номерлы кушымтаны әлеге карарга 4 номерлы кушымта (хезмәт урынында файдалану өчен) (китерелми) нигезендә территориаль зоналар чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга.

**Шәһәр Мэры** **И.Р.Метшин**

Казан шәһәре Думасының
2024 елның 7 августындагы
10-31 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр**

**ОЖ - 54**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы


**Территориаль зона**

| **Төс** | **Индекс** | **Территориаль зона төренең атамасы** |
|---|---|---|
| | ОЖ | Катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында шәһәр төзелешен зоналаштыру (территориаль зоналар) картасы фрагменты чиге |

**Башлыкның беренче урынбасары** **Д.Г.Калинкин**

Казан шәһәре Думасының
2024 елның 7 августындагы
10-31 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында чикләрендә территорияләрне комплексы үстерүне гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территорияләр картасы фрагменты**




**Шартлы билгеләр**

**ОЖ - 54**

Территориаль зона контурының тәртип номеры

Территориаль зона индексы

**Территориаль зона**

| **Төс** | **Индекс** | **Территориаль зона төренең атамасы** |
|---|---|---|
| | ОЖ | Катнаш торак һәм иҗтимагый төзелеш зонасы |
| | КРТ | Чикләрендә территорияләрне комплексы үстерүне гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территорияләр |
| | | Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре составында чикләрендә территорияләрне комплексы үстерүне гамәлгә ашыру күздә тотыла торган территорияләр картасы фрагменты чиге |

**Башлыкның беренче урынбасары** **Д.Г.Калинкин**